САГЫНУ ҺӘМ САБАК

«ВТ» хәбәрчесе уйланулары

> 2

БАТЫРЛЫК УРНӘГЕ

Казан Ратушасында Ватан Геройлары көнен билгеләп үттеләр

> 2

БАШЫҢА ТӨШСӘ...

Хәсрәт кемнәрнедер берләштерә, ә кайберәүләр аерылу чигенә барып җитә

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 183 (28956) | Шимбә | 10 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҖИДЕ КАТ УКЫП, БЕР ТҮЛИСЕ

БЕЛГЕЧЛӘР ЯЛГАННАН САК БУЛЫРГА КИҢӘШ ИТӘ

«Коммуналь түләү кәгазендә тагын бер юл барлыкка киләчәк!» «Торакны мәҗбүри иминиятләштергән өчен аена 1 мең сум акча ала башлаячаклар!» Соңгы көннәрдә социаль челтәрләр әнә шундый эчтәлектәге хәбәрләр белән тулды. Әлеге төр хезмәт өчен ягъни бер түләсәң, ул гомерлек булачак, дип тә куркыталар. Түлисеме, юкмы? Бу сорауга җавап бар.

Социаль челтәрләрдә таралган бу видеоязманы күрмичә калучылар сирәктер. Анда киләсе елның 1 гыйнварыннан торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә яңа юл барлыкка киләчәге турында хәбәр итәләр. Бу – торакны иминиятләштерү. Айлык түләү күләме дә билгеле. Аз да түгел, күп тә түгел – 1 мең сум. Исәп-хисап счетын тикшереп тормыйча, иминиятләштерү өчен бер тапкыр түләсәң, үзеңнән-үзе әлеге төр хезмәткә ризалык биргәнсең булып саналачак, имеш. Алга таба ул ай саен килеп торачак икән. Ә менә бер түләгәннән соң, торакны иминиятләштерүдән баш тартыра теләүчеләргә судтан башка юл юк, бу – бик озакка сузыла торган эш, фатирсыз калуыгыз да бар, дип кисәтәләр. Курыкмас җиреңнән куркырсың!

– Хәзер интернет заманы бит, коммуналь хезмәтләр өчен дә Дәүләт хезмәтләре порталы аша гына түләргә гадәтләндек, – ди Кукмарада яшәүче Гөлнара Иналетдинова. – Дөресен генә әйткәндә, ут-газ өчен күпме исәпләгәннәрен карап та тормыйм. Күпме язсалар, шулкадәр түлим. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дөресләк эзләүнең файдасы юк. Яңа төр түләү турында ишеттек. Тик торакны иминиятләштерүдән баш тарткан очракта, түләү кәгазендәге ул юлны ничек төшереп калдырырга икәне аңлашылмый. Интернетта счет-фактураның гомуми суммасы гына күренә бит.

Социаль челтәрләрдә таралган хәбәрдә торакны иминиятләштерү белән кайсы оешма шөгыльләнәчәге дә аермачык язылган. Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, әлеге иминиятләштерү компаниясенең «кайнар линия»сенә шалтыраттык.

– Мондый хезмәт торакны иминиятләштерү дәүләт программасы кысасында күрсәтелә. Ул гамәлдәге кануннарга каршы килми һәм киләсе елның 1 гыйнварыннан илнең аерым төбәкләрендә тормышка ашырыла башлаячак дип көтелә. Бу очракта торак бер айга иминиятләштереләчәк. Киләсе айда яңадан акча түлисе була. Иминиятләштерү очракларына торакның диварларына зыян килү, коммуникация системасы, сантехник җиһазлар керә. Болар барысы да аерым килешүдә күрсәтелачәк. Шунысы да бар: бу – ирекле хезмәт. Ягъни телисең икән – түлисең, теләмәсәң – юк, – дип аңлаттылар оешмада.

«Бу яңалык Татарстанга кагыламы? Иминиятләштерү өчен түләгән очракта килешүне кайдан аласы?» кебек сорауларга: «Бу хакта мәгълүмат юк», – дип кенә җавап бирделәр.

Идар Мөхәммәтҗанов

Башкаладагы икенче бер оешмада торакны иминиятләштерү буенча агент булып эшләүче Наҗия Мөбарәкшина сүзләренә караганда, бүген торакны иминиятләштерү – гайре табигый хәл түгел.

– Хәзер халыкны үгетләп йөрисе юк. Үзләре торакны иминиятләштерүебезне сорап мөрәҗәгать итәләр. Бу – ирекле хезмәт. Өстәвенә күп кешенең фатиры ипотекага сатып алынган, ә мондый очракта торакны иминиятләштерү – мәҗбүри шарт. Берүк хезмәт өчен ике тапкыр түләмисең бит инде. Чынга ашмас нәрсә белән башны бутамасыннар! – ди белгеч.

Татарстан торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов та шул фикердә. Аның әйтүенчә, халыкны махсус күркыталар.

– Беренчедән, әлеге яңалыкны кем-кайда хәбәр итүе турында бернинди рәсми мәгълүмат юк. Бу имеш-мимешне социаль челтәрләрдә генә тараталар. Ә аны кем уйлап табуы билгесез. Бу – ялган мәгълүмат. Махсус рәвештә халыкның ачуын чыгаралар. Димәк, бу кемгәдер кирәк. Коткыга бирелмәгез! Икенчедән, бүген коммуналь хезмәтләргә бәя арттыру мәсьәләсен күтәрү, гомумән дә, мантыйкка туры килми. Ник дигәндә, коммуналь хезмәтләргә бәяләр декабрьдә арттыгына бит әле. Гыйнварда ил халкы болай да яңа тарифлар буенча исәпләнгән түләү кәгазьләре алачак. Башка төр бәяләр арту булмаячак, – ди Дмитрий Романов.

Башкарма директор сүзләренә караганда, счет-фактурага яңа төр хезмәт өчен түләү кертү мәсьәләсе алай җиңел генә хәл ителми. Интернеттагы төрле имеш-мимешләргә ышанып, аларны туганнарга-дусларга таратырга керешкәнче, әнә шуны истә тотарга киңәш итә белгеч.

– Аерым бер идарәче оешманың яки иминият компаниясенең коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазенә өстәмә юл кертергә бернинди хокукы юк. Бу – сафсата! Белгәнебезчә, Казан халкына ишегалларыннан карны чыгарган өчен яңа түләү кертергә тәкъдим иттеләр. Бу хакта алдан ук мәгълүмат җиткерделәр. Кар чыгарган өчен түләргәме-юкмы икәнен күпкатлы йортларда яшәүчеләр фәкать үзләре хәл итәчәк. Моның өчен иң беренче чиратта җыелыш үткәрергә, фатир хуҗаларының фикерен белешергә. Ә торакны иминиятләштерү – һәркемнең үз иркендә. Сезне беркем дә мәҗбүр итә алмый. Бигрәк тә бүгенге заманда игътибарлырак булсагыз иде!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Куркыныч газ

Өч ел эчендә Татарстанда газ җиһазларының төзек булмавы аркасында 113 янгын очрагы теркәлгән. Барлысы 16 кеше һәлак булган. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчелек эшчәнлеге идарәсе башлыгы урынбасары Максим Трущин әйтүенчә, 18 очрак газ шартлауга бәйле. Фаҗигаләр газ баллоннарыннан дөрес файдаланмау сәбәпле килеп чыккан.

Янгында һәлак булган 16 кешенең 3е – балалар. 36 кеше җәрәхәтләнгән (4е – балалар).

Беренче тапкыр

Татарстанның ДРКБ Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә беренче тапкыр балага сөяк җелеге күчереп утыртуның тәүге этабы башкарылган. Яман шеш һәм кан авыруларыннан интегүчеләрне шундый ысул белән дәвалыйлар. Моның өчен балага иң элек төп кузәнәк күчереп утыртырга кирәк. Үзәктә шуңа ирешелгән дә инде.

«Татар-информ» хәбәренә караганда, яман шешле сабый хастаханәгә быел октябрь аенда эләккән. Гаять катлаулы бу эшләрне, Мәскәүнең Дмитрий Рогачев исемендәге үзәге табиблары белән берлектә, ДРКБ һәм КФУ белгечләре башкарган.

Сүз уңаеннан, 2023 елда Татарстан табиблары һәм урта медицина персоналы хезмәт хакына өстәмә 141,9 млн сум алачак. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин күрсәтмәсе Министрлар Кабинеты сайтында чыкты.

КАМАЗ тизләгеч арттыра

КАМАЗ гыйнвар – ноябрь айларында барлыгы 39,8 мең йөк машинасы җитештергән. Бу – узган елдагыга караганда 200гә күбрәк сан. Шул ук вакытта завод ноябрь аенда 3,8 мең машина комплекты (2021 елның шушы ук аендагыга караганда 350гә кимрәк) эшләп чыгарган. Монә тулы приводлы йөк машиналары җитештерүгә вакыт һәм көчнең күбрәк сарыф ителүе белән аңлаталар.

Шул ук вакытта КАМАЗның двигательләр заводы да, 2021 елдагы белән чагыштырганда, җитештерүне арттырган. Ноябрь аенда предприятие 4,5 мең двигатель эшләп чыгарган (узган елдагыдан 50гә күбрәк). Ә 11 айда 44,2 мең двигатель эшләп чыгарылган (узган елдагы күрсәткечтән 1 меңгә диярлек күбрәк).

Юньлегә илтми

Россияда наркотик куллану аркасында һәлак булган балалар һәм үсмерләр саны 2017 елдан бирле 2,5 тапкыр арткан. Россия Эчке эшләр министрлыгының наркотиклар әйләнешенә контроль буенча баш идарәсе җитәкчесе Иван Горбунов әйтүенчә, шушы чорда наркотиклар куллану сәбәпле исәптә торучы балигъ булмаганнар саны 40 процентка диярлек кимегән. Шуңа да карамастан, вазгыять катлаулы булып кала.

Белгеч аңлатып үткәнчә, үсмерләрнең наркотиклардан агулану, үлү очраклары арту аеруча борчу тудыра. Ул шулай ук 4 ел эчендә беренче тапкыр балаларның наркотикларга бәйле җинаять кылу очраклары артуын билгеләп үткән. Аның сүзләренә караганда, 2017 елдан бирле мондый җинаятьләр саны 56 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, быел гыйнвар аеннан июльгә кадәрге чорда илебездә 20,3 тонна наркотик һәм психотроп матдә законсыз әйләнештән алынган. Шул ук вакытта, әйтик, 2018 елның шушы ук чорындагыга караганда җинаятьләр саны ике тапкыр кимегән, 200 меңнән 105 меңгә калган. Ләкин хәзер мондый очраклар янә арткан.

Көн кадагында

«Онытылган» сумнар

Сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, халыкның күпчелеге коррупция очраклары белән хастаханә һәм сырхауханәдә, җиргә бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә, бакча һәм мәктәптә, милек килешүләре төзегәндә очраша. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көнендә узган республика форумында бу һәм башка бик күп көн кадагында торган мәсьәләләр күтәрелде.

pixabay.com

Татарстан Фәннәр академиясенең перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге директоры Марат Сафиуллин билгеләп узганча, шулай да алда санап узылган тармаклар арасында сәламәтлек саклау һәм мәгариф – ришвәт алу буенча иң еш телгә алына торганнары.

– Болар – чыннан да лидер. Ни өчен шулай килеп чыга? Әлеге тармакларның җәмгыятькә кыйммәте зур булса да, хезмәткәрләренең хезмәт хаклары аз. Һәм граждaннар җинаять эшләргә мәҗбүр була, – диде ул.

Аның сүзләренчә, бу хәл Татарстан, Россия өчен генә хас түгел, ә бөтен дөньяда шулай. Республикадагы вазгыятьне контрольдә тотар өчен халык арасында өледәнәле социологик сораштырулар уздырылуына да басым ясады ул.

Татарстан Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы Марс Бәдретдинов фикеренчә, бу мәсьәләдә түрәләр үзләреннән башларга тиеш. Чөнки коррупция хакимиятькә булган хөрмәтне һәм аның абруен киметә.

– Түрәгә халык дошманы итеп карыйлар. Әгәр ышаныч юк икән, безнең эшебезнең файдасы нида соң? – ди ул.

Һәм мисалга бер депутатның керемнәр турындагы декларациядә миллиард сум акчасын күрсәтергә «онытып» калдыруын китерде.

– Монда миллион турында сүз бармый, ә миллиард! Әлеге депутат табышны шәхси бизнесыннан алганлыгын әйтте. «Әгәр хезмәткәр минем менә шундый, ә үзенең менә шундый акча алуын белсә...» – дип акланмакчы булды намуссыз депутат, – диде Марс Бәдретдинов.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Көнбатыш Украинадан оятсызларча файдаланды, үзенә кирәген суырды, Донбасста геноцид һәм террорга күз йомып, илне колониягә әйләндерде. Хәзер Украина халкын, ерткычларча, Россиягә каршы көрәшү коралы буларак куллана.

(«Российская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЯҢА ЕЛ КАРШЫЛАУ

«АльфаСтрахование» хезмәте Россия халкыннан Яңа елны ничек каршы алырга җыенулары турында сорашкан.

41% >> гаилә белән бәйрәм итә

26% >> дуслар белән бәйрәм итә

16% >> Россия буенча сәяхәткә җыена

9,3% >> чит илгә очачак

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны	Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен** гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~
П2409 атнага дүрт тапкыр чыга	Ташламалы бәя **980 сум 10 тиен** гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

СССР: сагынулар һәм сабаклар

Декабрь – СССР дигән илне тудырган да, юкка чыгарган да ай. Советлар Союзын яшәүдән туктатып, аның урынына Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге (БДБ) дигән, гади халык аңлап бетермәгән ниндидер аморф берләшмә барлыкка китергән Беловежье килешүенә кул куелуга шушы араларда 31 ел тулса, СССР яралуга ай азагында төгәл бер гасыр була.

Җитмешне инде тутырам дигәндә капылт кына бакыйлыкка күчкән илне халыкның бер өлеше әле дә сагына. Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче үзәкләр үткәреп торган сораштыруларга караганда, Россия гражданнарының яртысы диярлек СССР таркалуны кирәкмәгән, аянычлы бер вакыйга, тарихи ялгыш дип кабул итә. Фаҗигагә тиңләүчеләр дә бөтенләй юк түгел.

Тарихи процессларны туктатып булмый – илләр ралган, барлыкка килгән кебек, кинәт кенә юкка чыгып та куялар. Кемнәрнедер һаман да утырып елатырлык шулхәтле нәрсә югалттык соң без? Ник һаман үткән белән яшибез? СССРга мөкиббән кавем өчен төп югалту – кешеләр арасындагы тигезлекнең калмавы, әлбәттә. Фәкыйрьлектәге шул тигезлекне сагынабыз без. Икенчедән, ностальгиянең бүгенгәчә саклануында хәзерге тормышның көтеп-көтеп тә без теләгән кимәлгә килмәве, җәмгыятебездәге күзгә төртелеп торган гаделсезлекләр ята. Бай катлау һаман да баеп, үзенә җирдәге оҗмах тудырып, рәхәт гизгәндә, аерым түрәләр дөньяның артына тибеп яшәгәндә, халыкның хәтсез өлешенең хәле мактанырлык булмау шундый кәефләр тудырмаса, бик гаҗәп тоелыр иде.

Яшьлекне сагынмый мөмкин түгел. Тик шунысын да билгелик: сораштыруларга ышанганда, саналган барлык сыктауларга да карамастан, халыкның бары 15–17 проценты гына талонлы, дефицитлы, чиратлы ул дәвернең кире кайтуы яклы икән. Монысы инде – «үлгән сыер» сөтле җәһәттә дә андый «мал»га бүтән кызыкмау дигән сүз…

Совет чоры ул – йөзләрчә миллион халык өстендә җиде дистә ел буе барган, чал тарихта күрелмәгән, дөньяви әһәмияте булып та, Россия өчен уңышсыз тәмамланган, ул гынамы, биредәге халыкка күрелмәгән тетрәнүләр алып килгән олы социаль-сәяси тәҗрибә. Ул – гражданнарга көчләп тагылган коммунистик идеология, тормыш рәвеше генә түгел. Ул – мифик «якты киләчәк» юлында миллионнар башына төшкән михнәтләр – гражданнар сугышыннан, коточкыч масштабтагы ясалма ачлыклардан, террор-репрессияләрдән башлап, Бөек Ватан сугышында ил биргән чутсыз корбаннар, матди югалтуларга кадәр – барысы да.

Коммунизм дип саташуның, аны төзегәндәге хилафлыкларның янә дә берсе – икътисади гына түгел, сәяси дә булган үзәкләштерү, вертикаль – олы илнең тар даирә, бер яисә берничә кеше акылы белән яшәве. Милләтләр мәнфәгатьләрен күрмичә, «совет халкы» дигән яңа төр «милләт» әвәләргә алыну, «тимер чаршау» торгызып, шуның артына посу, коралланууда чик-чаманы белмәү. Шушы ашкынулар режимның нигез ташларын ахыр чиктә тәмам какшатып, җимерелүне котылгысыз итте дә инде…

Ә бит 1922 елның декабрендә СССР федератив дәүләт буларак барлыкка китерелгән. Большевиклар, бик теләсәләр дә, губернияләрдән генә торган, милли территорияләр булмаган, халыклар ярты-йорты хокукларга гына ия яңа унитар дәүләткә исәп тота алмыйлар. Финляндия белән Польша Россия белән инде саубуллашкан, Балтыйк буе дәүләтләре суверенлык игълан иткән, башкалар да менә-менә табаннарын ялтыратырга тора. Шушы хәлләрдә бары милләтләргә үзбилгеләнеш вәгъдә итеп, республикалар, милли автономияләр төзеп кенә аларны элекке чикләрдә калдырып буласын Россиянең яңа хуҗалары яхшы аңлый. Ләкин… Дистә, дистә ярым ел үтеп, дәүләт власте ныгыгач, федератив мөнәсәбәтләр, белүебезчә, исемдә генә кала. Әмма шул рәвештә дә алар союздаш республикаларга демократия җилләре искән 1991 елда бәйсезлеккә ирешергә ярдәм итә.

Бүген Ленин һәм аның көрәштәшләренең тетмәләрен нәкъ менә союздаш һәм автономияле республикалар төзеп, халыкларда милли үзаң уяткан өчен тетәләр дә. Имештер ки, пролетариат юлбашчысы Россия астына 1922 елда бомба салып калдырган. Имеш, Татарстан урынына – Казан губерниясе, Урта Азия, Кавказ республикалары урынына Ташкент, Тифлис губернияләре һ.б. булса, кемнәрдер «XX гасырның төп геосәяси фаҗигасе» дип бәяләгән 1991 елның декабрь вакыйгалары яраласы булмаган.

Ә бит сәбәп гел башкада. Чын, тулы канлы федератив, кирәк икән, хәтта конфедератив мөнәсәбәтләр яшәгәндә, төбәкләр икътисади һәм сәяси ирекле булганда, СССР дигән дәүләт, ихтимал, әле дә исән булыр иде. Аерым халык яки милләт күпмилләтле ватанда кайгы күрми «җырлап» яши, аның хокукларын беркем дә чикләми, халык үссен, ныгысын өчен барлык шартлар тудырылган икән, андый милләтне, республиканы куып та читкә җибәрә алмыйсың.

Социализм төзергә алынган СССР исемле яңа империядә, төбәкләргә икътисади ирек тәтемәде генә түгел, икътисад һәрчак сәясәткә буйсынды. Без дөньяда иң яхшы танклар һәм иң начар автомобильләр җитештердек. Милитаризация дип үк атап булмаса да, яртылаш диярлек оборонага эшләгән халык хуҗалыгы тормыш сыйфатын яхшыртуда төп киртә булды. Безнең җырны җырласыннар дип, үз авызыбыздан өзеп, читләрне – ярты Африка белән ярты Азияне туендырып тору да яхшыга булмады. Шушы мавыгулар тормыш дәрәҗәсе буенча илне алдынгы дәүләтләрдән ярты гасырга артта тотты да инде. Шунлыктан Белоруссиянең урман әйләндереп алган Васкули авылына «мунча керергә» килгән Ельцин, Шушкевич һәм Кравчукның СССРга ясин чыгуы һич тә очраклы гамәл булмады, дияргә нигез бар…

СССР төзелү биредәге халыкка нужаны күп китерсә дә, вакыйга, дөнья масштабында алганда, олы әһәмияткә ия, дияргә мөмкин. Дөнья капиталына кеше чырае керү, аның хезмәт кешесе турында кайгырта башлавына нәкъ менә Октябрь инкыйлабы, СССР төзелү сәбәпче. Россиядәге хәлләр башка тарафларда да кабатланып, үзенә көн беткәнче, капитал, аңа хас булмаган юмартлык күрсәтеп, җәһәт кенә, сигез сәгатьлек эш көненнән башлап, төрледән-төрле социаль яклауларга кадәр – барысына да ризалашты. Ягъни Көнбатыштагы хезмәт кешесе башына ишелгән рәхәтлекләр бездәге михнәтләр хисабына булды.

КАДЕРЛЕ ҮРНӘК

9 декабрьдә Ватан Геройлары көне билгеләп үтелә. Быел ул «батырлык», «каһарманлык», «ватанпәрвәрлек» кебек төшенчәләрнең әһәмияте арткан мәлдә уза.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ил батырларын искә алу көнендә ветераннар һәм яшь активистлар белән бергә Казандагы Җиңү паркында урнашкан Мәңгелек утка чәчәкләр салды. Шуннан соң Казан Ратушасында узган тантаналы чарада катнашты. Мөхтәрәм кунаклар арасында Советлар Союзы Геройларының туганнары, Россия Геройлары, аларның якыннары һәм Социалистик Хезмәт Геройлары бар иде.

– Без үсеп килүче буынны сезнең үрнәктә тәрбияләү мөмкинлегенә ия булуыбыз белән бәхетле. Ватаннары хакына башларын салган каһарманнарыбыз да, бүген исән-сау булган батырларыбыз да, махсус хәрби операция зонасындагы яшь ир-егетләребез дә – чын үрнәк, – диде парламент рәисе, кадерле кунакларны бәйрәм белән котлап. – Ничек кенә теләсәләр дә, без Ватаныбыз һәм халкыбызга хөрмәт белән караудан туктамаячакбыз. Сызып ташларга тырышсалар да, тарихыбыз һәм мәдәниятебезне юкка чыгарырга юл куймаячакбыз. Кызганыч, явыз көчләр төп басымны яшь буынга ясый. Шуңа да, зинһар өчен, мөмкинлегегез булса, балалар һәм яшьләр белән ешрак очрашыгыз.

Фәрит Мөхәммәтшин яшь буынны ватанпәрвәрлек һәм илгә тугрылык рухында тәрбияләүнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын мисаллар белән дә дәлилләде.

– Шушы көннәрдә Мәскәүдә Россия Геройлары белән очрашуда катнаштым. Анда үзебезнекеләр – Татарстан егетләре дә чыгыш ясады. Алар барысы да Татарстанга карата ихтирам һәм яратуларын белдереп, чыгышларын «Без сезне сынатмабыз!» дип төгәлләде. Менә күрәсезме, лаеклы буын үстерү ни дәрәҗәдә мөһим! – диде ул.

Шуннан соң парламент рәисе совет хәрбие Александр Тодоровскийның: «Геройлар герой булып тумый, алар сугышларда туа», – дигән сүзләрен искә алды. Һәм үз исеменнән: «Геройлар бөек хезмәтләрдә туа», – дип өстәде.

– Һәр буынга нинди дә булса сынау аша узарга туры килә. Ата-бабаларыбыз өлешенә Бөек Ватан сугышы тисә, алардан яшьрәкләр сугыштан соңгы елларның ачысын күргән. Бүгенге менә – махсус хәрби операция. Безгә Россия үсешенә аяк чалырга тырышучыларга каршы көрәшергә туры килә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Россия Герое, «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы рәисе Газинур Хәйруллин чыгышын бик кыска тотты. Әмма республикада яшәүче барлык Геройлар исеменнән, ихтирам һәм һәрдаим күрсәтелә торган ярдәм өчен, Хөкүмәткә рәхмәт сүзләрен кызганмады.

Ватан алдындагы бурычларын үтәгәндә гомерләре өзелгән батырларның якыннары бу көнне шулай каршылый. Чәчләренә чал төшсә дә, яралар әле төзәлеп бетмәгән. Ә Украинадагы махсус хәрби операциядә батырларча һәлак булган егетләрнең әти-әниләре һәм якыннарының күз яшьләре дә кибеп бетмәгән.

Без исә Россия Герое Дамир Исламовның апасы Динара Алтынова белән сөйләшә алдык. 25 яшьлек егетнең гомере 7 мартта өзелә. Аның экипажы, дошман белән бәрелешкәндә, биш танкның дүртесен юк итә.

– Дөресен генә әйткәндә, минем бу бәйрәм турында ишеткәнем дә юк иде. Тормыш ишеттерде… Хисләремне аңлата алмыйм. Ил батырларының әти-әниләре, туганнары, үзләре белән очрашу – зур бәхет инде югыйсә. Без бит алар белән шушындый чараларда гына очраша алабыз. Шул ук вакытта күңелне сагыш һәм сагыну хисе өзгәли. Ә энем өчен горурлык хисе яшәргә, башкаларга ярдәм кулы сузарга этәрә. Күптән түгел генә без, мобилизацияләнгән егетләргә һәм аларның якыннарына ярдәм итәр өчен, аның исемендәге хәйрия фонды ачтык. Шулай итә-итә, бераз онытылабыз инде, – дип сөйләде ул, күз яшьләрен яшерергә тырышып.

Лилия ГЫЙМАЗОВА



Ватан Геройлары көне уңаеннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Социалистик Хезмәт Герое, «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасының мактаулы рәисе Илдус Мостюков белән очраштылар.
Рөстәм Миңнеханов Илдус Мостюковны бәйрәм белән котлап, аның ил оборонасын ныгытуга керткән өлешен билгеләп үтте. Билгеле булганча, галим-конструктор 1980 елда Бердәм дәүләт радиолокацион танып белү гомуми хәрби системасын булдырганы өчен Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була. Илдус Мостюков – «үзебезнеке – чит» танып белү системасын төзүчеләрнең берсе.
Кичә Рөстәм Миңнеханов һәм Минтимер Шәймиев башкаланың Горький урамында Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы ветераны Борис Кузнецовка мемориаль такта да ачтылар.
Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Борис Кузнецов – олы батырлык иясе, 19 яшендә Советлар Союзы Герое булган чын ватанпәрвәр. «Борис Кирилловичның тормышы – Ватанга тугрылык һәм мәхәббәт, ныклык һәм фидакарьлек, тиңсез батырлык һәм каһарманлык үрнәге», – диде Президент. Ул Советлар Союзы Героеның гомере буе актив җәмәгать эшчәнлеге алып баруын да әйтте. «Аның каһарманлыгы – махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен үрнәк. Борис Кирилловичның бетмәс көч-куәте, киләчәккә ышаныч белән каравы, тормыш зирәклеге турындагы якты истәлек йөрәкләребездә мәңге сакланачак», – диде Рөстәм Миңнеханов.
Герой турындагы истәлекләре белән Минтимер Шәймиев тә уртаклашты. «Мин Борис Кириллович белән шәхсән таныш идем. Ул данлы тормыш юлы үтте. Аның тарихы – яшьләребезгә үрнәк», – диде Дәүләт Киңәшчесе.

ТӨП ЗАКОН БӘЙРӘМЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия Федерациясе Конституциясе көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Россия Федерациясе Конституциясе көне – төрле милләттә һәм диндә булган гражданнарны Ватанның тарихи бөеклеген саклауга һәм арттыруга омтылышта берләштерә торган бәйрәм белән котлыйм.

Россия үзенең яңа Төп Законына моннан 29 ел элек, 1993 елның 12 декабрендә ия булды. Илнең һәм аның уртак язмыш белән берләшкән күпмилләтле халкының озак чорларга үсеше хакында җәмәгать килешүенең нәтиҗәсе булган канун федератив корылышка һәм нәтиҗәле җирле үзидарәгә нигез салды. Законның һәм бәйсез суд эшчәнлегенең өстенлеген раслады. Граждан тынычлыгын һәм этникара татулыкны ныгыту, бай тарихи-мәдәни мирасны саклап калу гаранты булды. 1993 елгы Конституция Россия җәмгыятен төзүнең төп принципларын – гражданның хокуклары һәм ирекләренең үзгәрмәс хәлен, дәүләт бердәмлеген һәм территориаль бөтенлекне саклауны, идеология күптөрлелеген, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне яклауны ышанычлы беркетте. Шушы нигезләмәләрнең какшамас булуын раслап, 2020 елда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның башлангычы белән гамәлгә ашырылган һәм илнең күпчелек халкы хуплаган конституция реформасы бу сәяси нигез документны шактый көчәйтте. Социаль гарантияләрне һәм илкүләм мәнфәгатьләрне яклау мөмкинлекләрен арттырды, дәүләтнең суверенитетын ныгытты. Һичшиксез, Конституциянең бай куәтен алга таба да арттыру күп очракта федераль һәм региональ дәрәҗәләрдәге законнар чыгару эшчәнлегенең сыйфатыннан, килештерелгән һәм системалы булуыннан торачак.

Бүген Татарстан ил Конституциясендә күрсәтелгән юнәлештә эзлекле бара. Тормыш сыйфатын яхшырту, алга таба да сәяси һәм социаль-икътисади үсү өчен хокукый нигезләрне киңәйтү максатларында республика законнарын камилләштерә. Күпмилләтле Россиянең граждан бердәйлеген һәм аның бердәмлеген ныгыту, халыклар арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлекнең гасырлык традицияләрен саклау сәясәтен даими алып бара. Куелган максатларга ирешү өчен әле бик күп хезмәт итәргә кирәк булса да, иң мөһиме – Төп Законны үтәп һәм хөрмәт итеп уртак мәнфәгатьләр һәм ниятләр белән яшәү. Әйдәгез, шушы юлда бер-беребезгә уңышлар телик. Барыгызга да нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек һәм республика, бөтен Россия хакына иҗади хезмәтегездә уңышлар!

Бәйрәм белән! Россия Федерациясе Конституциясе көне белән!

ГАДЕЛЛЕК ТЫНЫЧЛЫККА КИТЕРСЕН

Бүген – Халыкара Кеше хокуклары көне. Республикада яшәүчеләрне бу уңайдан Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская котлады.

«1948 елның 10 декабрендә Кеше хокукларының гомумдекларациясе, шәхеснең һәм аның хокукларының иң мөһимлеген билгеләгән документ кабул ителә, – диелгән котлауда. – Бу истәлекле вакыйга белән, раса, җенесе, теле, дине, милли яисә социаль чыгышы, сәяси карашына бәйсез рәвештә, барлык кешеләргә бертигез хокуклар игълан ителә. Бу көн безгә үз хокукларыбыз һәм бурычларыбызны белү, тирәбездәгеләргә ихтирамлы мөнәсәбәттә булу зарурилыгын искә төшерү мөмкинлеге бирә.

Тиңдәшсез республикабызда төрле диннәр һәм милләтләр, берләшмәләр һәм телләр күп гасырлар буе үзара янәшә атлый. Ләкин иң мөһиме – бердәмлек һәм бер-беребезне ихтирам итү.

Без катлаулы чорда яшибез. Шуңа күрә кайвакыт гадәти булмаган ашыгыч карарлар кабул итәргә туры килә. Мондый вакытта кеше хокукларын яклау – кайчандагыга караганда да мөһимрәк. Башта – ковид, ә быел катлаулы геосәяси вазгыять тыныч тормышыбызга катгый үзгәрешләр кертте. Ватаннан читтә катлаулы хәлләрдә калган хәрби хезмәткәрләрнең һәм илебездә яшәүчеләрнең хокукларын яклау төп бурычларның берсенә әйләнде.

Мәңгелек кыйммәтләр – тигезлек һәм гаделлек, тынычлык, иминлек, иртәгәге көнгә ышаныч китерсен!»

Дәүләт Советында

Парламент утырышы – киләсе атнада

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы 15 декабрьдә үткәрелә. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 14 мәсьәлә, шул исәптән 6 республика законы проектын, 1 федераль закон проектын һәм Оренбург өлкәсе Законнар чыгару җыенының закон инициативасын карап тикшерергә ниятли.

Көн тәртибенә кертелгән барлык 6 республика законы проекты беренче укылышта каралачак. Аерым алганда, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматлар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итү, Сиктерме-Хузангаево авылының исеме үзгәрү сәбәпле, Әлки районы чикләрен билгеләү, дәүләти гражданлык хезмәте, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм гражданлык оборонасы турында республика законнарына үзгәрешләр кертү хакында закон проектлары беренче укылышка әзерләнгән. Моннан тыш аттракционнарның техник торышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле турында республика законы проекты беренче укылышта карап тикшереләчәк.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, утыз сигезенче утырышта 2023 елга Дәүләт Советында закон проектларын эшләүнең үрнәк планын һәм Дәүләт Советының Россия субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең үрнәк планын карап, тулаем кабул итү күздә тотыла.

Утырышта шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Кодексына үзгәрешләр кертү хакында федераль закон проектын Дәүләт Думасына кертү турында Дәүләт Советының закон инициативасы каралачак. Биредә сүз этил спиртын һәм спиртлы продукцияне ваклап сатуга җаваплылык билгеләү турында бара.

Алдагы утырыш кысасында, вәкаләтләре срогы чыгу сәбәпле, Иҗтимагый палатаның яңа составын булдыру мәсьәләсе каралачак. Дәүләт Советы кандидатларның өчтән бер өлешен (20 кеше) раслый. Вакантлы 20 урынга 29 гариза тапшырылган. Парламент утырышында рейтинг нигезендә тавыш бирү процедурасы күздә тотыла.

Президиум утырышында Мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов мәдәни мирас объектлары турында республика законын гамәлгә ашыруга мониторинг йомгаклары буенча чыгыш ясады.

«ОНЫТЫЛГАН» СУМНАР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Коррупция очраклары авыл хуҗалыгы тармагында да очрый.

– Элеккеге җитәкчеләр җирләрне үзләштерәләр дә анда берни дә утыртмыйлар. Нәтиҗәдә бик күп җирләр ташландык хәлдә ята, фермалар бушап калды. Ә халык нишләргә тиеш? Эшләргә эш юк икән, авыллар, әлбәттә, бетә, – диде ул.

Торак-коммуналь хуҗалык тармагы – коррупция еш очрый торган тагын бер өлкә. Торак-коммуналь хезмәтләргә, каты көнкүреш калдыкларына әледән-әле бәя арту халыкның ачуын чыгара. Татарстан Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсендә генә дә быел әлеге өлкә буенча халыктан – 2600, Дәүләт торак инспекциясендә 8000 мөрәҗәгать кабул ителгән. Аларның күпчелеге гомуми торак милкенә һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүгә кагылышлы.

Ришвәтчелек чәчәк аткан тагын бер тармак – ритуаль хезмәт күрсәтү. Белгечләр әйтүенчә, бу – контрольгә иң аз алына торган өлкә. Россия Прокуратурасы әлеге өлкәдә 120 меңнән артык закон бозу очрагын ачыклаган. Монда бәяләрдәге тәртипсезлек, каберлекләр һәм муниципаль җирләрне сату, мәет җирләнәчәк җирне алдан бирү хокукының шәхси кулларга күчүе кебек закон бозу очраклары еш күзәтелә икән. Кайбер зиратларда якыннарын җирләр өчен хәтта тулы бер рәтне алдан алып кую һәм каберләрне юлларда казу очраклары да ачыкланган.

Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча Тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары Марсель Дулкарнаев китергән мәгълүматлар буенча, республикада ришвәт бирү һәм алуга бәйле яңа очракларның меңнән артыгы тикшерелгән. Тикшерү комитеты коррупциягә бәйле 1255 эш буенча тикшерү уздырган.

– Бу – бик зур саннар. Җинаятьләрнең якынча 60 проценты тирәсе ришвәт алу һәм бирүгә бәйле, – диде Марсель Дулкарнаев.

Россия Прокуратурасы мәгълүматлары буенча, быелның гыйнварыннан алып октябрьгә кадәр 30 меңнән артык коррупциягә бәйле җинаять очрагы ачыкланган. Шуларның 5 меңгә якыны – ришвәт бирү, 4 меңе – ришвәт алу буенча. Марсель Дулкарнаев әйтүенчә, ике арада акча йөртүче арадашчылар саны елдан-ел арта.

Форумда катнашучылар 2024 елны Татарстанда коррупциягә каршы көрәш елы дип игълан итү тәкъдиме белән чыктылар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Коррупция: журналист карашы» республика бәйгесендә «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Зөһрә Садыйкова беренче урынны алды.

БЕРГӘ БУЛГАНДА АВЫРЛЫК ЧИГЕНӘ

Гыйбрәт

Авырлык-борчуларны төрле кеше төрлечә кабул итә. Гаиләләр өчен бала авыру – бигрәк тә зур сынау. Бу хәсрәт кайбер гаиләләрне тагын да берләштерә, кемнәрдер аерылу чигенә барып җитә. Шөкер, авылдашларым Люда һәм Рәфкать Саттаровлар беренче төркемгә карый. «Без авырлыкларны бергә җиңдек», – ди алар.

Рәфкать күршебездә үсте. Тырыш, тыныч, уен-көлкеле булды. Ул елларда сагынып искә ала торган хатирәләр бик күп. Искиткеч бердәм булып, ярдәмләшеп, бик күңелле яшәдек. Бөтен тирәбез белән үзен армиягә озаттык, исән-сау хезмәт итеп кайтуына өйдәгеләреннән ким куанмадык.

Ул елларда түбәнрәк сыйныфта укучы малайларны да комбайнчы ярдәмчесе итеп эшкә алалар иде. Рәфкать үзе ничәнче сыйныфны тәмамлаганнан соң эшли башлавын хәтерләми, әмма мөстәкыйль штурвал артына утырганчы инде берничә комбайнчы белән, берничәшәр ел эшләп, тәҗрибә тупларга өлгергән була. Әлеге алган тәҗрибә киләчәктә егеткә бик тә ярап куя, чөнки армиядән кайткач, бераз район оешмаларында эшли дә, «Татарстан» хуҗалыгына кайтып, комбайнга утыра. Урак беткәч, тракторга күчә, чылбырлысында да, тәгәрмәчлесендә дә эшли. Бүгенгәчә шулай. Үткән егерме бер ел эчендә мактау-бүләкләре дә күп. Комбайнчылар арасында да һәрчак лидерлар сафында була, тракторчылар арасында да сынатмый. Алай гына да түгел, 2007 елда районның «Язгы кыр эшләре батыры» исемен яулый, республикадагы сукачылар ярышында катнашып, дүртенче урын ала, ничә еллар рәттән районда алдынгылар сәхнәсенә күтәрелә…

…Рәфкатьләр өйләнешкәч тә, кызлары Лилия өч яшькә җиткәнче күршеләр булып яшәдек. Тормыш иптәше Люда – Мари Иле кызы. Безнең авылдагы туганнарында торып, СПТУда укыды, аннан клуб мөдире булып эшләде. Бик тә ачык, шат күңелле Люда безгә бик якын булып калды. 2003 елда алар башка чыгып, авылның икенче очына күченде. Ике елдан Лилиягә иптәшкә Рәмис исемле энекәш тә алып кайттылар.

– Балтачтагы бала тудыру йортыннан безне сез сау-сәламәт дип кайтарып җибәрделәр. Улыбызга бик тиз салкын тисә, еш авырса да, шикләнмәдек. Өч айдан соң күренергә баргач, аякларына нык итеп басмый дип, Казанга невропатологка җибәрделәр… – дип искә ала ул көннәрне Люда. – Аннан эндокринологка да күренегез әле, диделәр. Менә шуннан калкансыман бизендә кимчелек таптылар һәм даими дару эчәргә куштылар…

Тик Рәмисләрендә алга китеш сизелми, барыбер әледән-әле салкын тиеп авырый. Биш айлык чагында «обструктив бронхит» диагнозы белән аларны хастаханәгә салалар. Өч тәүлек чиратлашып саклаганнан соң (уллары тоташ диярлек система астында була), үзгәреш күренмәгәч, районныкылар Казан табибларын чакырта. Бу вакытка инде Рәмиснең температурасы да нык күтәрелгән була. Санавиация белән килгән табиб хәлнең җитдилеген яшерми, зәңгәрләнеп беткән малайга карап: «Мин баланы алып китмим. Казанга кадәр барып җитмәячәк», – ди. Бу сүзләрне ишетеп торган әти-әни ниләр кичергәндер, әмма, бәхетләренә, чираттагы системадан соң Рәмиснең температурасы төшә. Казан табибы да фикерен үзгәртә… Шул китүдән Рәмис белән Люда Казанда өч ай ятып кайта. Әйткәндә генә тиз һәм ансат: баласы өч көн реанимациядә булганда сәгате түгел, минутлары елга тиң тоела әни кешегә. Ярый әле, юлында миһербанлы кешеләр очрый: аның ничек өзгәләнгәнен күреп, берничә минутка гына булса да, улы янына кертәләр. Күп еллар үтсә дә, бу күренеш бүген дә күз алдында Люданың: улының бөтен җирендә – торба-шланглар… Әнисе кергәч, Аллаһның рәхмәте белән, биш айлык сабый, күзен ачып, әнисенә карый. Бу караш Людага ышаныч-өмет бүләк итә. Баласының исәнлеген белү иң зур бәхет була, әле күп еллар кирәк булачак сабырлык-ныклыкка да нигез сала ул…

Бу чорда, дәваланудан бигрәк, алар күпсанлы тикшеренүләр үтә. Кызганычка, тикшеренгән саен диагнозлар исемлеге арта, Казаннан инде алар бер кочак диагноз белән кайта. Генетик авыру да, йөрәгендә бик җитди чир дә табыла. «Мондый диагноз белән бер яшькә кадәр яши алмыйлар», – дигән табиблар хөкеме иң авыры була.

Рәмиснең йөрәгенә кичекмәстән операция ясатырга кушалар. Мәскәүгә барырга киңәш бирүчеләр дә була. «Күрәчәгең булса, анда да саклап кала алмаслар, һич югы Казанда ярдәм кирәк булса, туганнар килә ала», – дип, алар Казанда калырга була. Тик операция ясатканчы да шактый көтәргә туры килә: әле Рәмискә чираттагы салкын тия (баланың иммунитеты шулкадәр какшый: аны авырудан саклау бик кыен була), ул терелсә, кардиохирургиянең реанимация бүлегендә урын булмый. Шөкер, бу операция уңышлы чыга. Тик ике яшь тулгач, аларга барыбер Мәскәүгә генетик үзәккә барырга туры килә. «Рәхмәт төшкере, ул чакта Мәскәүдә яшәгән мәрхүмә авылдашыбыз Фирания апа бик булышты, бик күп ярдәм итте, без аңа гомеребез буе рәхмәтле», – ди Люда. Ул чакта Рәмискә бер диагноз куйсалар, моннан ике ел элек тагын тикшеренү үтәргә чакырып, бу юлы икенче диагноз куялар…

– Башка тикшеренүләр үтмәскә булдык, алардан берни дә үзгәрми, – ди бүген Саттаровлар. – Шөкер, улыбыз яшьтәшләре белән бергә башлангыч мәктәптә укый алды, аннан Арча районындагы Кенәр махсус мәктәбендә тугызынчы сыйныфны тәмамлады, бүген Арчадагы 120 нче училищеда икенче курста укый, бик тырышып һөнәр үзләштерә. «4ле» һәм «5ле»ләргә, стипендия алып укый. Дүрт малай әби белән бабайда фатирда торалар. Сөенеп бетә алмыйбыз: әби белән бабай да бик ярата, бик мактыйлар үзен. Без аны кечкенәдән кеше белән аралашудан тыймадык, дәваларын да өзмәдек, авыру дип санамадык та. Өйдәге бөтен эшләрдә көченнән килгәнчә булышты. Әле дә кайткач, малларны ул карый… Дуслары да күп. Апасы Лилия, сеңлесе Рәзилә белән дә бик дуслар…

Әйе, Рәмис бераз уңайлангач, Саттаровлар өченчегә бик тә сөйкемле тагын бер кыз алып кайталар. Бүген Рәзилә дүртенче сыйныфта укый. Уку алдынгысы, Балтачка, күрше авылдагы мәдәният йортына биюгә йөри, «Иминлек тәгәрмәче» конкурсында катнашырга әзерләнә. Лилия апалары инде урта мәктәптән соң, медкөллиятне кызыл дипломга тәмамлаган. Бүген фармацевтика юнәлешендә эшли, шул ук вакытта КНИТУда, читтән торып, югары белем ала.

Үткәннәрне искә алганда алар әле дә тыныч кына сөйли алмый. Ул елларның һәр көне, һәр вакыйгасы йөрәкләрендә уелып калган. Борчу-авырлыклар инде артта калган булсын, үз тырышлыклары, хәләл көчләре, хезмәтләре белән булдырган муллыкның бәрәкәтен күреп, куанып яшәргә язсын!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышын 2022 елның 15 декабрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 9 декабре
№ 1716-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
3. «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 354-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 356-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 31 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 358-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 362-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы территориясендә аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында» 351-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 361-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
10. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
11. Вәкаләтләре туктатылган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы таныклыгы турында.
12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195018-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юллар буенча билгеләнмәгән урыннарда йөргән өчен салына торган административ штрафлар күләмен арттыру өлешендә).
14. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 49 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында (кисәтүдә күрсәтелгән таләпләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар хакында мәгълүмат тапшыру өлешендә).

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 9 декабре
№ 1717-VI ДС

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
2022 елның 07 декабрендә теркәлде,
№ 10149

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ БОЕРЫК

25.11.2022 Казан ш. № 3605-р

«Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясын, «Оешмалар милкенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 1^1 статьясын, «Россия Федерациясе Салым кодексының 378^2 статьясының 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән:

1. Үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектларының 2023 елга исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.
2. 2023 елга исемлекне билгеләнгән тәртиптә Салым федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.
3. 2023 елга исемлекне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru. адресындагы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары Э.М.Дияровка йөкләргә.

Министр Ф.Ә.Әһлиуллин

Искәрмә: Россия Федерациясе Салым кодексының 378^2 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеге кушымтасы белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында (адресы: https://mzio.tatarstan.ru/perechen-obektov-nedvizhimosti-na-2023-god.htm) урнаштырылган.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Спортта югары күрсәткечләргә ирешүе, физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Армия үзәк спорт клубы» федераль автоном учреждениесенең спорт командасы спортчы-инструкторы (теннис һәм бадминтон буенча), Россиянең атказанган спорт мастеры **Кодермәтова** Вероника Эдуард кызы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Шаһиәхмәтов** Ришат Йосыф улы **«Татарстан автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен нефть сәнәгате ветераннары: **Әхмәдиев** Тәлгать Җәүдәт улы, **Калачев** Геннадий Федорович, **Митина** Гөлчәчәк Мөксин кызы, **Сыраев** Руслан Сөләйман улы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Зеленодольскиның А.М.Горький исемендәге заводы» акционерлык җәмгыяте техник директорының төп җитештерү буенча урынбасары **Бондин** Александр Сергеевичка, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте махсус конструкторлык бүлеге әйдәүче инженер-конструкторы **Буткова** Татьяна Васильевнага, «Ар Си Эр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Павлов** Константин Вальмировичка, «Кориб» автомобильләр ремонтлау заводы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Стульников** Денис Валерьевичка, «Казан электр техникасы заводы» акционерлык җәмгыяте баш конструкторы – махсус конструкторлык бюросы башлыгы **Хөснетдинов** Тимур Мансур улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Чаллы шәһәренең «15 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Ганиева** Гөлназ Фирдәвес кызына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының 1 номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физика укытучысы **Гришина** Татьяна Борисовнага, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Лениногорск шәһәренең 8 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология һәм география укытучысы **Кутасова** Наилә Кяшаф кызына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «1 номерлы Урыссу башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Матвеева** Галина Владимировнага, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Академик Р.З.Сәгъдиев исемендәге урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Победимская** Светлана Евгеньевнага, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Сәмикова** Гөлназ Әмирҗан кызына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Имән Кискә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Шәймөхәммәтова** Алия Мөхәммәтҗан кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Әгъзамова** Рима Рәшит кызына, «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе балет артисты **Мөхәммәтҗанов** Илмир Рим улына, «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе балет артисты **Хәбәбетдинов** Артур Рим улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Союз-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчелек комплексы операторы **Фадеев** Александр Ивановичка **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«П.В.Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Алимов** Рәмис Рәшит улына, «Агро Л» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте комплексы башлыгы (идарәчесе) (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Булатов** Фәргать Кәлимулла улына, «Лаеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Чистай» холдинг компаниясе акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Закиров** Гомәр Фәрит улына, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары **Залаков** Наил Ринат улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының финанслау бүлеге башлыгы **Злобин** Сергей Николаевичка, «Козлова Мария Ивановна» крестьян (фермер) хуҗалыгы директоры (Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы) **Козлов** Николай Владимировичка, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге өлкән белгече **Латыпова** Светлана Закирҗан кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге башлыгы **Митрофанова** Раиса Михайловнага, «Зәй ашлык кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте директоры **Фәрдиев** Рафис Ривгать улына, «Мелиорация» Алга механикалаштырылган күчмә колоннасы ачык акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Хәйретдинова** Фидания Рәис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Васильева** Елена Сергеевнага, «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең практика мөдире **Хәсәнова** Наилә Иса кызына, «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Нурлат районара почтамты башлыгы **Ногуманов** Рафиз Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Булган хәлләр

ГАЗИНУР МОРАТ КАЗАНДА БУЛМАГАНДА

Газинур Морат санаторийда ял итә. Ашханәдә бер танышын очрата бу. Гадәттә, Казанга якын санаторийларда дәваланучылар шимбә-якшәмбедә өйләренә кайтып килә бит. Бу очрашу дүшәмбе көнне була.

– Кайтып килдеңме өеңә? – дип сорый Газинур Морат танышыннан.

– Әйе, – ди тегесе.

– Казан нихәлдә анда? Тәртипме?

– Без Казанда булмаганда анда һәрвакыт тәртип инде, Газинур абый! – дип әйтеп куя танышы.

МӘДИНӘ ГАЙНУЛЛИНАГА – 20!

Хатын-кызның яшен сорамыйлар, диләр. Әмма кайвакыт сорыйлар да икән. Әлмәт театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты Мәдинә Гайнуллинадан бервакыт сораганнар:

– Мәдинә, сиңа ничә яшь?

– 20.

– Ике ел элек тә шулай дигән идең бит!

– Мин бүген бертөрле, иртәгә икенче төрле сөйләп йөри торган кеше түгел! – дигән Мәдинә.

МАРАТ ЗАКИР ДА ЙӨЗӘ

«Равил Фәйзуллин йөзүләре» күп еллар уздырылып килә. Җәйнең матур бер көнендә язучылар су коенырга чыгып китәләр. Су коенырга гына түгел, иң осталар киң елгаларны, зур күлләрне йөзеп чыга. Лаеш районына автобуста бер төркем язучылар кайтып бара. «Син дә йөзәсең мәллә бүген?» – дип сорап куя Марат Закирдан Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла. «Йөзәм, ник… Нишләп әле мин йөзмәскә тиеш?» – дип җавап кайтара Марат Закир. Язучылар арасында шаярулар бик үзенчәлекле була кайвакыт. Ркаил Зәйдулла әйтсә әйтеп куя: «Ну, егетләр, Марат Закир елганың теге ярына йөзеп чыга алса да, йөзеп чыга алмаса да – безнең өчен икесе дә уңай нәтиҗә».

ӘМИР КЫЗЫКЛАРЫ

ӘМИР – ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫНДАГЫ АВЫЛ

Баюлары җитте

Харис абзыйларда – өй туе. Күрше авылдан чуаш дусты да килгән. Моңарчы да яхшы гына сыйланган дус өй туенда тагын берничәне җибәргәч, тәмам мәлҗерәгән дә ишек бусагасына авып йоклап та киткән. Шул мәлдә Харис абзыйларга күршеләре килеп керә һәм бусагада яткан адәмне күргәч әйтеп куя: «Баюлары җитте бу Харисларның, ишек бусагасына да кеше җәя башладылар!»

Ишекне тот, мин сызам…

Элмәле дигән чуаш авылы Әмиргә якын гына. Ир-атлар шул авылга барып, баш төзәтеп кайтучан иде. Ләкин чуаш апалар да төшеп калганнардан түгел: кул эшенә оста татарларга аларның йомышы чыгып кына тора. Шулай бервакыт Әхмәт абзый да баш төзәтеп алырга була. Чуаш апасы бераз салып бирә дә: «Ишекне ясаткан идем, озынрак булган, рәткә кертче», – ди. «Була ул, – ди Әхмәт агай. – Алайса, акбур белән сызыйк. Син ишекне тот, мин сызам». Килешә хуҗа хатын. Ишекне тоткан килеш ун минут чамасы басып тора чуаш апа, абзыйның тавыштыны юк, ул чын-чынлап «сызган» икән…

Карчык, сулпа бир!

Гайсә җизни шофер булып эшләгәндә, борт ычкынып китеп, тешләрен койды. Шифаханәдән кайткач, хатынына әйтә икән бу:

– Карчык, сулпа бир әле!

– Нәрсә, нәрсә?

– Суны да аңламыйсың, ас инде, ас.

Академик булган

Шулай бервакыт әни миңа: «Лашманнан Әхәт малае академик булган», – дигән шатлыклы хәбәр җиткерде. Мин аптырап калдым: югары белем дә алмаган килеш ничек академик булалар икән? Әнинең үз сүзе сүз: син беләсеңме, мин беләмме? Чынлыкта исә Әхәт малае укуында академик ял алган булып чыкты.

Селкенеп кенә булырмы?

Әхмәт абзый читтән яшь кызга өйләнеп кайта. Берничә көннән яшь хатын колхозга эшкә чыга. Аннан сорыйлар:

– Ничек яшисез соң, Мәдинә?

– Шөкер, өй кирәк-яраклары сатып алдык. Бераз селкенсәк, сыерлы да булырбыз әле…

– Ай-һай, – ди шунда бер хатын. – Селкенү генә сыерлы итәрме икән, җиң сызганып эшләргә кирәк, эшләргә.

Иң авыры – Ләләгә

Колхозлашу елларында терлекчеләрне бүләкләү өчен махсус премия билгелиләр. Әмма колхоз рәисе премияне бухгалтер Ләләгә бирү яклы. Шунда тимерчелектә эшләүче абзый әйтеп куя: «Иң авыр эшне бухгалтер башкара, премия дә аңа тиеш». Менә шуннан соң халык теленә «Иң авыры Ләләгә» дигән әйтем кергән иде, шул әйтем кирәксә дә, кирәкмәсә дә кулланылышта булды.

Миндар ӘГЪЛӘМОВ

Авыр ел булды



vk.com

Икътисади кризис, эпидемия, дәүләтара низаглар – нинди генә хәлләр булмады быел. Бәлки, мин әле кияүгә дә чыгып куярмын.

* * *

Бу ел шундый авыр булды ки, лотерея билеты алсаң, фатирыңны югалтырга мөмкинсең.

* * *

Елда бер генә Көлке көне. Башка көннәр бер дә көлкеле түгел.

* * *

– Бөтен нәрсә артты инде быел.

– Алай димә, хезмәт хакы артмады.

* * *

Сатуда кыйммәтрәк бәядән узган еллар календарьлары бар.

* * *

Нинди елда чыккан булуына карамастан, һәр телевизор бер үк әйберне күрсәтә.

* * *

Nokia телефоны календарена ышансаң, ахырзаман 2087 елны булачак.

* * *

Узар еллар… дигән идем мин. Һәм хаклы булдым. Еллар узды.

ВСЕ БЕСПЛАТНО АЛАРДА

Хорошо иметь в деревне
Әтиең-әниеңне,
Можно на все лето туда
Илтергә бәбиеңне.

Аннан аласың с собой
Обратно киткәндә
Мясо, молоко, бәрәңге
Беткәненнән беткәнгә.

Даже курылары у них
Бушка күкәй салалар,
И бесплатно огородтан
Яшелчәләр алалар.

Кыяр, помидор, луклары
В огороде, не ступать,
В городе ведь барысын да
Можно только покупать.

Хорошо живут в деревне
Все свое ведь у них там,
Соленьялар, вареньялар
Можно достать погребтан.

А воздухы какой чиста,
Вдоволь можно суларга,
Они даже хлор не сыпят
Эчә торган суларга.

Фрукты, ягодалар белән
Туп-тулы бакчалары,
Не пойму куда девают
Пенсия акчаларын?..

«Предки» зовут жить авылга,
В голову тай типмәгән,
Яхшы знаю балчык эшен,
Зря чыгып китмәгән!!!

Интернеттан

ЧЕМПИОН АТЫ КЕМГӘ БУЛЫР?



vk.com

Узган юлы футбол буенча дөнья чемпионатында җиңүләрне күрәзәче сигезаяк әйтеп бара иде. Быел ул сигезаякны нишләттегез, дөресен әйтегез?!

* * *

Хатын-кызлар сериаллар карап күпме яшь түккән булса, ир-атлар футбол карап шулкадәр яшь түгә.

* * *

– Россия кешесе футбол буенча дөнья чемпионатында җиңү яулагач нишли?

– Компьютер уенын сүндереп йокларга ята.

* * *

«Париж-Дакар»да ел да җиңүче «КамАЗ»ларны футбол буенча мундиальгә һәм «Евровидение»гә җибәреп карарга кирәк.

* * *

Безнең җыелма команда, ниһаять, дөнья чемпионатына эләгәчәк! Бишәр «Сникерс» кәгазе җыеп тапшырган кешеләргә быел шундый мөмкинлек бирелде.

* * *

Франция җыелмасы өчен быел бөтен Африка җан атты.

* * *

– Әй, малай, финал уенына мондый кыйммәтле билетны кайдан алдың?

– Әтием сатып алды.

– Ә үзе кайда?

– Өйдә билет эзли.

Әз-мәз мәзәк



– Әй! Кил әле монда!

– Үзең кил.

– Син якынрак бит.

* * *

– Ой, шундый матур песи! Кушаматы ничек моның?

– Тима.

– Тимофейме?

– Тимерһади.

* * *

Музыка дәресендә:

– Вәлиев! Син шундый начар җырлыйсың. Сиңа туп-туры эстрадага барырга кирәк.

* * *

Кул бармакларының ни өчен кирәк булуы аңлашыла. Ә аяк бармаклары?

* * *

– Матурым, машина кабынмый.

– Күпме әйтергә була сиңа, мин булмаганда машинага сул яктан утырасы, дип.

Фамилияң Матуров, кемнәр куйган?

Вакыт-вакыт колакка кызыклы фамилияләр чалынып китә. Татарстан Кинематографистлар берлегенең элеккеге рәисе, режиссер Илдар Матуровның фамилиясе шундыйлардан. Элек тә аптырый идем: каян килгән мондый сирәк фамилия? Шушы арада үзе белән танышырга җай чыкты. Һәм барын да үзеннән сораштым.

Татарда ничек бит: бабаң Гайфулла булса, син Гайфуллин, Шәйдулла булса – Шәйдуллин. Ә Матуровның бабасы Матур булганмы? Илдар әфәнде әйтүенчә, элеккеге заманда төрки халыкларда Матур дигән исем шактый таралган булган. Фамилия килеп чыгышының бер версиясе шул исемгә бәйле. Икенче версия – матуридизм дигән сүздән чыккан булуы ихтимал. Ислам динендәге дәгъвәт-фәлсәфә белән бәйле юнәлеш бу. Ничек кенә булмасын, Илдар Матуровның фамилиясен еш кына тәхәллүс, ягъни псевдоним дип уйлыйлар икән. Иҗат кешесе булуы да үзенекен итә, күрәсең. Бер эшлекле очрашу вакытында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев: «Каян килде сиңа мондый фамилия? Ирләргә бик туры килми инде бу, хатын-кызларга күбрәк туры килә», – дип шаярткан.

Үзенчәлекле фамилиясенең гел игътибар үзәгендә булуына Илдар Матуров инде күнеккән. Шулай да Мәскәүдә укыган елларын искә төшерә. «Мәскәүлеләр өчен синең фамилияң берни дә аңлатмый, шуңа күрә кабатлап та сорамыйлар, псевдоним дип тә шикләнмиләр», – ди режиссер. Ә Казанда була торган иң еш вазгыять мондый. Берәр рәсми оешмада документ тутырганда операционист кыз синең фамилияңне сорый. «Матуров» дигән сүз ишеткәч, аның белән шаяралар,

танышырга телиләр дип уйлый. Паспортны күрсәткәч кенә чибәр кыз документ тутыруын дәвам иттерә. «Фамилияң Матуров, кемнәр куйган?» – диярсең.

P.S. *Сүз уңаеннан, бәлки укучыларыбыз арасында да үзенчәлекле фамилияле кешеләр бардыр? Ничек яшисез сез мондый фамилия белән? Безгә языгыз әле.*

Мач әйткән!

Шәүкәт ГАЛИЕВ, татар шагыйре

Тормышны артык шомартма. Шома юл тайгак була…

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 383

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+